ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 20.11.2020 г. Казань № 242-72/кс-2020

2021 елга «Сельхозжилсервис» муниципаль унитар предприятиесе өчен эчәргә яраклы суга тарифлар билгеләү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Сельхозжилсервис» муниципаль унитар предприятиесе (алга таба – «Сельхозжилсервис» МУП) өчен эчәргә яраклы суга әлеге карар кушымтасы нигезендә календарь бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2021 елның 1 гыйнварыннан 2021 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Сельхозжилсервис» МУП Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартларына туры китереп, ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турындагы карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
20.11.2020 № 242-75/кс-2020
карарына кушымта

# Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Сельхозжилсервис» МУП өчен эчәргә яраклы суга 2021 елга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Техник суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | |
|---|---|---|---|
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр |
| | Азнакай муниципаль районы | | |
| 1 | «Сельхозжилсервис» МУП* | 29,47 | 29,86 |

<*>Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм
теркәү бүлеге